Республика Татарстан
Совет Чукмарлинского сельского поселения Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге советы

РЕШЕНИЕ
2023 ел, 24 ноябрь

КАРАР
№ 14

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Кама транспорт прокуратурасының 2023 елның 27 июлендәге № 23/1-02-2023 номерлы протесты, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Чукмарлы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының 2022 елның 25 ноябрендәге 19 номерлы Чукмарлы авыл җирлеге советы карары белән расланган «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлекнең 4.1 пунктын төшереп калдырырга;

2) 3.6.1 пунктының «й» пунктчасында «тимер юллар,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 3.7.2 пунктындагы «д» пунктчасында «һәм тимер юл» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 3.11.8, 3.11.9, 3.11.10 пунктларында 3.11.10 бүлегендә «(тимер юл)» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җир кишәрлекләре хокукы бирүчеләр үзләре милкендәге, биләгән яисә файдаланган җир кишәрлекләреннән Сосновский борщевикын алу буенча чаралар уздырырга тиеш, ә Сосновский борщевикын җир кишәрлекләреннән һәм җирләрдән алып ташлау чараларын, аларга дәүләт милке чикләнмәгән килеш, җирле үзидарә органнарын гамәлгә ашыра. Сосновский борщевикын алу чаралары күрсәтелгән ысулларның берсе яисә комбинациясе юлы белән уздырыла:

- химик яктан - гербицидлар һәм (яисә) арборицидлар белән үсү чыганакларын сиптерү;

- механик яктан - чаптыру, коры үсемлекләрне җыю, тамыр системасын казып алу;

- агротехник яктан - туфрак эшкәртү, күпьеллык үләннәр чәчү.

6) 4.2.7 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән http://pravo.tatarstan.ru адрес буенча игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга:

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Чукмарлы авыл җирлеге
Советы рәисе И.Х.Хадиуллин